ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле $14^1$ өлеш өстәргә:

«$14^1$. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта башкарыла.

Күрсәтелгән бурыч тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә хәл ителгән очракта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү мондый билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш);

2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Пенсиягә өстәмә билгеләү Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләгән затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта билгеләнә.

Күрсәтелгән бурыч пенсиягә өстәмә билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә хәл ителгән очракта пенсиягә өстәмә билгеләү мондый билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.».

**3 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ өлеш өстәргә:

«$9^1$. Пенсиягә өстәмә билгеләү муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта башкарыла.

Күрсәтелгән бурыч пенсиягә өстәмә билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә хәл ителгән очракта пенсиягә өстәмә билгеләү мондый билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.».

**4 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле $19^1$ өлеш өстәргә:

«$19^1$. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта башкарыла.

Күрсәтелгән бурыч тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә хәл ителгән очракта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү мондый билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.».

**5 статья**

Әлеге Закон 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 13 ноябрь
№ 69-ТРЗ